МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.11.2019 г.Казань № 995

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 2 декабрендә 5899 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2019-2021 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган мөһим бәяләү критерияләрен раслау турында» 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2019-2021 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган мөһим бәяләү критерияләрен раслау турында» 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«2019-2021 елларга» сүзләрен «2019-2022 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «2019-2021 елларга» сүзләрен «2019-2022 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

тексттагы «2019-2021 елларга» сүзләрен «2019-2022 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

боерыкка кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 23 маендагы 398 номерлы боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.11.2019 995 номерлы боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2019 елның 26 апрелендәге 344 номерлы карары белән расланган «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашу өчен кадидатураларны килештергәндә кулланыла торган мөһим бәяләү критерияләре

| «2019-2022 елларга чит илләрдә яшәүче ватандашларның үз ирекләре белән Татарстан Республикасына күчеп килүенә булышлык күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасында катнашуга кандидатураларны килештергәндә кулланыла торган бәяләү критерияләре[1] | Бәяләү критерияләре-нең мөһимлеге |
|---|---|
| 1. Яше | Максимум 15 |
| • 18-29 яшь | 15 |
| • 30-34 яшь | 12 |
| • 35-39 яшь | 9 |
| • 40-44 яшь | 6 |
| • 45 яшькә кадәр һәм эшкә сәләтле булган яшькә кадәр | 5 |
| • Хезмәткә яраклы яшьтән өлкәнрәкләр | 4 |
| 2. Мәгариф | Максимум 12 |
| • Гыйльми дәрәҗәсе | 12 |
| • Мәгариф учреждениеләрендә алынган югары белеме: • | |
| - Россия Федерациясендә (СССР) | 10 |
| - Башка дәүләтләрдә | 8 |

[1] Алга таба – Бәяләү критерияләре

| | |
|---|---|
| • Урта һөнәри белем, һөнәри белем бирү | 7 |
| 3. Эш тәҗрибәсе | Максимум 10 |
| • 5 яшьтән олы | 10 |
| • 3-5 ел | 8 |
| • 1-3 ел | 5 |
| • Бер елдан азрак | 2 |
| 4. Хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру (гариза бирү вакытына) | Максимум 15 |
| • Мәгариф, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, спорт, мәгълүмат-коммуникация технологияләре, машина төзелеше өлкәләрендә. | 15 |
| • Башка өлкәләрдә | 10 |
| 5. Актуаль фәнни һәм технологик проблемалар белән шөгыльләнүче белгечләр һәм галимнәр | 10 |
| 6. Тормыш иптәшенең һөнәри белеме булу | 4 |
| 7. Балигъ булмаганнарны да кертеп, кандидат белән бергә күченә торган балаларның булуы | 4 |
| 8. Россия Федерациясе һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында белем ала торган студентлар (алынган белемен исәпкә алмыйча) | 30 |